СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРЖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29.06.2021 Әгерже шәһәре № 10-7

«Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясен төзү турында» Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Советының 2020 елның 22 октябрендәге 2-2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Кадрлар үзгәрүгә бәйле рәвештә, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составына үзгәрешләр кертеп, аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).
2. Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составын раслау турында» 2021 елның 29 апрелендәге 9-7 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны «Татмедиа» АҖ филиалының «Әгерже хәбәрләре» («Агрызские вести») газетасында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Әгерже муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru).
4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2021 елның 29 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.
5. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Советының законлылык, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет Рәисе А.Р. Вәлиев

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль
районы Советының
22.10.2020 №2-2
карары белән расланган
(29.06.2021
№10-7 карары редакциясендә)

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составы**

1. Вәлиев Азат Рөстәм улы - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башлыгы, комиссия рәисе;
2. Зарипова Альмира Таһир кызы - Әгерҗе районында социаль яклау идарәсе башлыгы, комиссия рәисе урынбасары (килештерү буенча);
3. Хәкимова Эльвира Рәис кызы - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең баш белгече, комиссиянең җаваплы секретаре;

**Комиссия әгъзалары:**

1. Обухова Ксения Александровна - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең баш белгече;
2. Әхмәтова Айгөл Фәрит кызы - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторының әйдәүче белгече;
3. Сафиуллина Вәсилә Гарәфетдин кызы - «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы;
4. Сергеева Татьяна Сергеевна - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте бүлеге башлыгы;
5. Хуҗиәхмәтов Тимур Рәсим улы - Россия Эчке эшләр министрлыгының Әгерҗе районы буенча бүлеге башлыгы урынбасары (килештерү буенча);
6. Петряева Елена Анатольевна - Россия Эчке эшләр министрлыгының Әгерҗе районы буенча ОДН бүлегенең өлкән инспекторы (килештерү буенча);
7. Караянин Виталий Дмитриевич - «Әгерҗе үзәк район хастаханәсе» ДАССУ психиатр-наркологы (килештерү буенча);
8. Мифтахова Ксения Сергеевна - “Әгерҗе үзәк район хастаханәсе” ДАССУ район педиатры (килештерү буенча);
9. Шәйдуллин Айрат Разакович - Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш идарәсенең Әгерҗе муниципаль районы буенча бүлекчәсе башлыгы, эчке хезмәт подполковнигы (килештерү буенча);
10. Мурзин Сергей Емельянович - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчесе (килештерү буенча).